СОВЕТ ВЕРХНЕСУБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮГАРЫ СУБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» сентября 2018 ел №86

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Югары Субаш авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 нче елның 18 сентябрендәге 85 номерлы Югары Субаш авыл җирлеге Советы карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Советы тарафыннан Югары Субаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 18 сентябрендәге 10 номерлы Югары Субаш авыл җирлеге Башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2019 елда Югары Субаш авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- Югары Субаш авылында: янгынга каршы гидрант урнаштыру; зират коймасын һәм инвентарьлар өчен бинаны ремонтлау;

- Көшкәтбаш авылы: Һ. Такташ урамы буенча җәяүлеләр күперен ремонтлау, инвентарьлар цчен бинаны һәм зират коймаларын ремонтлау, балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм Центральная урамы буенча урнаштыру;

- Сасна Пүчинкәсе авылында: "Бибимәмдүдә" паркы коймасын ремонтлау, мемориаль такта урнаштыру, балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм "Бибимәмдүдә" паркында урнаштыру, "Бибимәмдүдә" чишмәсен төзекләндерү;

- Түбән Субаш авылында: зират коймасын төзекләндерү;

- Каенсар авылында: янгынга каршы гидрант урнаштыру.

- элеккеге Бакча авылында тарихи такта урнаштыру.

ЮК ӘЙЕ".

3. Югары Субаш авыл җирлеге Советы карары нигезендә, аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җыелган акчаны экономияләү очрагында, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

4. Әлеге карарны «Хезмәт» район газетасында һәм pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар аңа имза куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы Вафин Р.Б.